ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына һәм «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр округы статусын бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 11 маенда
кабул ителде

**1 статья**

«Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре һәм аның статусы турында» 2004 елның 15 сентябрендәге 46-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 8 – 9; 2007, № 12 (II өлеш); 2008, № 7 (II өлеш), № 12 (VI өлеш); 2012, № 1; 2014, № 12 (IV өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1 статья. **Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләре турында**

Казан шәһәреннән (административ үзәк) һәм аның янәшәсендәге терртиторияләрдән торучы Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 2 нче кушымта) нигезендә билгеләргә.».

**2 статья**

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеген төзү, аның чикләрен билгеләү һәм аңа шәһәр округы статусын бирү турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 47-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 1 (III өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«2 статья. **«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләре турында**

Чаллы шәһәреннән (административ үзәк) торучы «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге территориясе чикләрен карта-схема (әлеге Законга 1 нче кушымта) һәм чикләрнең картографик тасвирламасы (әлеге Законга 2 нче кушымта) нигезендә билгеләргә.».

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 26 май
№ 30-ТРЗ